ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Югары Ослан районында яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2013 ел № 131-ФЗ Федераль законы, “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советының 04.06.2020 ел № 58-670 карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турында нигезләмә нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләргә;

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карап тикшерү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп билгеләргә (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы).

2.2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча 2024 елның 13 декабреннән 2025 елның 11 гыйнварына кадәрге чорда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә иҗтимагый фикер алышулар үткәрү.

2.3. Проект экспозициясен үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасы, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы, 2024елның 13 декабреннән 2025

елның 11 гыйнварына кадәр эш көннәрендә 08:00 дән 12:00 сәгатькә кадәр, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты. Тәкъдимнәр, искәрмәләр 2024 елның 13 декабреннән 2025 елның 11 гыйнварына кадәр сишәмбе һәм пәнҗешәмбе 08:00 сәгатьтән 12:00 сәгатькә кадәр язма рәвештә һәм (яисә) Alina.Sagdeeva@tatar.ru электрон почтасы аша кабул ителә.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга проект буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәрне Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетына иҗтимагый фикер алышуларны оештыруны техник яктан тәэмин итәргә, шул исәптән экспозицияләр уздырганда да.

5. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

5.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне тәэмин итәргә.

5.2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5.3. 2024 елның 13 декабреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын урнаштырырга.

5.4. Экспозицияне Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында, 2024 елның 13 декабреннән 2025 елның 11 гыйнварына кадәр эш көннәрендә 08:00 сәгатьтән 12:00 сәгатькә кадәр, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында оештырырга.

5.5. Иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин